МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

Казан № 1367/14

«Ятим балаларны һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларны, ятим балалар һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларны махсуслаштырылган торак фондының торак урыннары белән тәэмин итүне оештыру турында»

«Ятим балаларны һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларны торак урыннары белән тәэмин итү турында» һәм «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү турында» 2013 елның 12 гыйнварындагы 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Ятим балаларны һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларны торак урыннары белән тәэмин итү турында» һәм «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү турында» 2013 елның 12 гыйнварындагы 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру буенча чаралар турында» 04.05.2013 № 312 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә ятим балаларны һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларны, ятим балалар һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларны махсуслаштырылган торак фондының торак урыннары белән тәэмин итү максатларында боерык бирәм:

1. Махсуслаштырылган торак фондының торак урыннары белән тәэмин ителергә тиешле ятим балаларның һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларның, ятим балалар һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларның реестрын формалаштыру һәм раслау регламентын әлеге боерыкка кушымта нигезендә расларга (1 нче кушымта).

2. Ятим балаларны һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларны, ятим балалар һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларны махсуслаштырылган торак фондының торак урыннары белән тәэмин итү реестры формасын әлеге боерыкка кушымта нигезендә расларга (2 нче кушымта).

3. Махсуслаштырылган торак фондының торак урыннары белән яллау шартнамәләре буенча әлеге боерыкка кушымта (3 нче кушымта) нигезендә агымдагы елда тәэмин ителергә тиешле ятим балаларның һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларның, ятим балалар һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларның җыелма исемлеген расларга.

4. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы каршындагы Торак комиссиясе турында нигезләмәне әлеге боерыкка кушымта (4 нче кушымта) нигезендә расларга.

5. «Ятим балаларны һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларны, ятим балалар һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларны махсуслаштырылган торак фондының торак урыннары белән тәэмин итүне оештыру турында» 01.10.2013 № 3639/13 Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгын үз көчен югалткан дип танырга.

6. Әлеге Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән минстры урынбасары С.В. Гыйниятуллинга йөклим.

Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары - министр

Э.Н. Фәттахов

Татарстан
Республикасы Мәгариф
һәм фән министрлыгы
боерыгына
1 нче кушымта

**Махсуслаштырылган торак фондының торак урыннары белән тәэмин ителергә тиешле ятим балаларның һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларның, ятим балалар һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларның реестрын формалаштыру һәм раслау РЕГЛАМЕНТЫ**

1. Әлеге Регламент белән Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан Махсуслаштырылган торак фондының торак урыннары белән тәэмин ителергә тиешле ятим балаларның һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларның, ятим балалар һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларның (алга таба – ятим балалар) «Ятим балаларны һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларны торак урыннары белән тәэмин итү турында» һәм «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү турында» 2013 елның 12 гыйнварындагы 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Ятим балаларны һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларны торак урыннары белән тәэмин итү турында» һәм «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү турында» 2013 елның 12 гыйнварындагы 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру буенча чаралар турында» 04.05.2013 № 312 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә махсуслаштырылган торак фондының торак урыннары алучыларның реестрын формалаштыру һәм раслау тәртибе билгеләнә.

2. Реестрны формалаштыру ятим балаларның законлы вәкилләренең «Ятим балаларны һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларны торак урыннары белән тәэмин итү турында» һәм «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү турында» 2013 елның 12 гыйнварындагы 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясы белән билгеләнгән тәртиптә бирелгән үтенечнамәләре нигезендә Министрлык тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Реестрны алып бару һәм актуальләштерү ятим балаларның әлеге Регламент белән билгеләнгән тәртиптә муниципаль берәмлекләр башкарма комитетлары тарафыннан бирелгән шәхси эш кәгазьләрендәге мәгълүмат нигезендә гамәлгә ашырыла.

3. Реестрны формалаштыру Министрлык тарафыннан ятим балалар турындагы белешмәләрне торак урыннарга мохтаҗ булган, җирле үзидарә органнарында исәптә торган, 18 яшькә җиткән, шулай ук балигъ булганчы ук тулысынча хокукый сәләткә ирешкән йә әлеге затларның мәгариф учреждениеләрендә, халыкны социаль яклау учреждениеләрендә, сәламәтлек саклау учреждениеләрендә һәм закон белән

билгеләнгән тәртиптә булдырыла торган ятим балалар өчен учреждениеләрдә булу срогы тәмамланган очракта, шулай ук һөнәри белем алуы тәмамланган йә чакыру буенча хәрби хезмәт узуы тәмланган, йә төзәтү учреждениеләрендә җәза алу чоры тәмланган очракта, ятим балалар турындагы белешмәләрне әлеге реестрга кертү юлы белән гамәлгә ашырыла.

4. Муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары елына ике мәртәбә, ярты еллык тәмамланганнан соң килүче айның 20сеннән дә соңга калмыйча, махсуслаштырылган торак фондының торак урыннары белән тәэминителергә тиешле ятим балаларның шәхси эш кәгазьләрен Министрлыкка җибәрәләр.

5. Министрлык ятим балаларның шәхси эш кәгазьләре кергәннән соң 10 эш көне эчендә аларны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы каршындагы Торак комиссиясенә (алга таба – Торак комиссиясе) җибәрә.

6. Торак комиссиясе ятим балаларның шәхси эш кәгазьләрен алганнан соң 7 эш көне эчендә Торак комиссиясе утырышын билгели һәм ятим балаларны махсуслаштырылган торак фондының торак урыннары белән тәэмин ителергә тиешле ятим балалар реестрына кертү йә әлеге реестрга кертүдән баш тарту турындагы карарны карый һәм чыгара. Торак комиссиясе тиешле карар кабул иткәннән соң 10 көн эчендә ятим балаларның законлы вәкилләренә ятим балаларны реестрга кертү турында (йә реестрга кертүдән баш тарту турында) хәбәр итела.

7. Реестрга кертүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

- ятим баланың «Ятим балаларны һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларны торак урыннары белән тәэмин итү турында» һәм «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү турында» 2013 елның 12 гыйнварындагы 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 1 өлешендә күрсәтелгән гражданнар категориясеннә кермәве;
- гариза бирүче тапшырырга тиешле документлар тапшырылмау яисә тулысынча тапшырылмау;
- әгәр тиешле документ гариза бирүченең үз инициативасы буенча тапшырылмаган булса (мондый соратып алынучы документлар яисә мәгълүмат шушы органнарның яисә оешманың үзләрендә булмау тиешле гражданнарның реестрга керүе хокукын раслаган очраклардан гайре), дәүләт хакимияте органының, җирле үзидарә органының яисә дәүләт хакимияте органына һәм җирле үзидарә органына буйсынучы органның ведомствоара гарызнамәгә җавабы соратып алынучы документ һәм (яисә) мәгълүмат булмавын таныклавы;
- тапшырылган документларда ятим бала турында дөрес булмаган белешмәләр булу.

8. Реестр ятим балалар торак урыннарына мохтаҗ буларак исәпкә куелган хронология тәртипбендә формалаштырыла.

9. Бер үк көнне исәпкә куелган ятим балалар реестрга алфавит тәртибендә кертелә.

10. Реестрдан төшереп калдыру өчен нигез түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

- Министрлыкка махсуслаштырылган торак урыннарын яллау шартнамәләре буенча бирү турында муниципаль берәмлекләр башкарма комитетларыннан алынган белешмәләр яисә исемлеккә кергән ятим балаларга социаль яллау шартнамәләре буенча торак урыннары бирү турындагы белешмәләр керүдән;

- Министрлыкка муниципаль берәмлекләр башкарма органнарыннан ятим балаларның «Ятим балаларны һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларны торак урыннары белән тәэмин итү турында» һәм «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү турында» 2013 елның 12 гыйнварындагы 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 1 өлешендә билгеләнгән таләпләргә туры килмәслек хәлләр килеп чыгу турында белешмәләр керүдән.

Ятим балаларны реестрдан төшереп калдыру әлеге пунктта күрсәтелгән белешмәләр Министрлыкка кергән көннән 7 эш көненнән дә соңга калмыйча Министрлык тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Министрлык ятим балаларга реестрдан төшереп калдыру турында 10 көн эчендә хәбәр итә.

11. Реестрны актуальләштерү, исемлеккә кертелгән ятим балаларның шәхси күрсәткечләренә алар мәгълүм булганнан соң 7 эш көненнән дә соңга калмыйча, үзгәрешләр кертү юлы белән Министрлык тарафыннан гамәлгә ашырыла..

12. Реестр нигезендә Министрлык агымдагы елга әлеге боерыкка кушымта (3 нче кушымта) нигезендә махсуслаштырылган торак фондының торак урыннары белән тәэмин ителергә тиешле ятим балаларның җыелма исемлеген формалаштыра.

13. Җыелма исемлек «Ятим балаларны һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларны торак урыннары белән тәэмин итү турында» һәм «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү турында» 2013 елның 12 гыйнварындагы 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә формалаштырыла һәм “Шәхси белешмәләр турында” 2006 елгы №152-ФЗ Федераль закон белән билгеләнгән таләпләрне үтәгән килеш бирелә.

14. Махсуслаштырылган торак фондының торак урыннары алучы ятим балалар реестры, хисап чорыннан соң килүче елның 1 гыйнварына хәлендә килеш, 20 гыйнвардан да соңга калмыйча, Торак комисссиясе тарафыннан раслана.

15. Әлеге Регламентның гамәлдә булу срогы даими була.

Татарстан Респуб
Мәгариф һәм фән
боерыгына
2 нче кушымта

Махсуслаштырылган торак фондының торак урыннары белән тәэмин ителергә ти
ятим балаларның һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларның, ятим бала
һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларны
РЕЕСТРЫ

| ıс. | Туган датасы | Теркәлү урыны, яшәү урыны адресы | Паспорт күрсәткечләре | | | Салым түләүченең идентификацион номеры | Торак шартла яхшыртуда мохтаҗлар сыйфатында г алуны раслый торган докуме | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Серия-се, номеры | Бирү датасы | Кем биргән | | Исәпкә кую датасы | До ном |

**Татарстан Респу**
**һәм фән министр.**
**3 нче кушымта**

этнамәләре буенча агымдагы елга махсуслаштырылган торак фондының торак урыннары беләі
м балаларның һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларның, ятим балалар һәм ата-ана к
калган балалар арасыннан булган затларның

ЖЫЕЛМА ИСЕМЛЕГЕ

| **:.** | **Туган датасы** | **Теркәлү урыны, яшәү урыны адресы** | **Паспорт күрсәткечләре** | | | **Салым түләүченең идентификацион номеры** | **Торак шартла яхшыртуда мохтаҗлар сыйфатында і алуны раслый торган докуме** | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | **Сериясе, номер** | **Бирү датасы** | **Кем биргән** | | **Исәпкә кую датасы** | **До ном** |

**Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгына 4 нче кушымта**

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы
каршындагы Торак комиссиясе турында
НИГЕЗЛӘМӘ

## 1. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1.1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы каршындагы Торак комиссиясе (алга таба – Торак комиссиясе) даими була.

1.2. Торак комиссиясе махсуслаштырылган торак фондының торак урыннары белән тәэмин ителергә тиешле ятим балаларның һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларның, ятим балалар һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларның реестрын формалаштыруга һәм раслауга бәйле мәсьәләләрне карау максатында булдырыла.

1.3. Торак комиссиясенең шәхси составы Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары - Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры боерыгы белән раслана.

Торак комиссиясе Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары - Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры боерыгы белән раслана һәм үзгәртелергә мөмкин.

1.4. Торак комиссиясе үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Торак кодексына, Татарстан Республикасы законнарына, әлеге Нигезләмәгә һәм башка норматив хокукый актларга таяна.

1.5. Торак комиссиясе карары мәҗбүри характерда була.

## 2. БУРЫЧЛАР ҺӘМ ХОКУКЛАР

2.1. Торак комиссиясенең төп бурычлары түбәндәгеләр:

- яллау шартнамәләре буенча махсуслаштырылган торак фондының торак урыннары белән тәэмин ителергә тиешле ятим балаларны һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларны, ятим балалар һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларны (алга таба – ятим балалар) исәпкә алу;
- махсуслаштырылган торак фондыннан торак урыны алуга чират билгеләү;
- яллау шартнамәләре буенча махсуслаштырылган торак фондының торак урыннары белән тәэмин ителергә тиешле ятим балалар реестрын (алга таба – ятим балалар реестры) раслау;
- агымдагы елда яллау шартнамәләре буенча махсуслаштырылган торак фондының торак урыннары белән тәэмин ителергә тиешле ятим балаларның җыелма исемлеген (алга таба – ятим балаларның җыелма исемлеге) раслау.

2.2. Торак комиссиясе түбәндәгегә хокуклы:

- үз компетенциясенә кергән мәсьәләләр буенча карарлар кабул итәргә;
- кабул ителгән карарларны үтәлешен тикшереп торырга;

- җирле үзидарә органнарыннан билгеләнгән тәртиптә Торак комиссиясе компетенциясенә кергән барлык мәсьәләләр буенча материаллар һәм мәгълүмат соратып алырга.

## 3. ЭШНЕ ОЕШТЫРУ

3.1. Торак комиссиясе эшчәнлегенә комиссия рәисе җитәкчелек итә, ул:
- комиссия эшен оештыра;
- комиссия утырышын билгели;
- комиссия утырышларында рәислек итә;
- комиссия әгъзаларына йөкләмә бирә.

Комиссия рәисе вакытлыча булмаган очракта, аның вазыйфаларын комиссия рәисе урынбасары үти.

3.4. Торак комиссиясе утырышлары ай саен уздырыла һәм, аларда комиссия әгъзаларының яртысыннан артыграгы катнашса, тулы вәкаләтле булып санала.

3.5. Торак комиссиясе утырышлары беркетмә белән рәсмиләштерелә.

3.4. Карарлар утырышта катнашкан комиссия әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән кабул ителә.

3.5. Торак комиссиясе карарларына комиссия рәисе һәм секретаре имза сала.

3.6. Торак комиссиясен оештыру ягыннан тәэмин итү Министрлыкның опека, попечительлек һәм педагогик ярдәм бүлегенә йөкләнә.